ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-21, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
№ 13 «19» август 2024 ел.

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 12 нче мартындагы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында"гы 8 санлы карары үз көчен югалтуын тану хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль канун, 2020 елның 23 декабрендәге «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2220 санлы карар, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы канун, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 09 ноябрендәге 28 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты

карар итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 12 нче мартындагы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында"гы 8 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев